ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15) Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендәге торак пунктларда газ китерү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында 2022 елның 1 гыйнварыннан яңа гына файдалануга тапшырылган 1,2 МПа кадәр, шуны да кертеп, басымлы газ бүлү челтәренең газүткәргечләренә карата оешмалар.»;

2) 5 статьяның 9 пунктында «әлеге Законның 3 статьясындагы» сүзләреннән соң «2 өлешенең 15 пунктын,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 99-ТРЗ